# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Югары Кибәхуҗа торак пунктының гражданнар җыены буенча.

**2019 елның 8 декабре Югары Кибәхуҗа авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Югары Кибәхуҗа торак пунктында 2019 елның 7 декабрендә һәм 8 декабрендә узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Югары Кибәхуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- су башнясын сатып алу һәм урнаштыру;
- юлларны кардан чистарту;
- санкцияләнмәгән чүплекне бетерү;
-лампалар, урам яктырткычлары, электр җиһазлары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су алу башнясы павильонын ремонтлау һәм эшләрне башкару өчен төзелеш материаллары сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 296 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 171 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашучы 171 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Югары Кибәхуҗа торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Югары Кибәхуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- су башнясын сатып алу һәм урнаштыру;
- юлларны кардан чистарту;
- санкцияләнмәгән чүплекне бетерү;
- лампалар, урам яктырткычлары, электр җиһазлары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
- су алу башнясы павильонын ремонтлау һәм эшләрне башкару өчен төзелеш материаллары сатып алу, кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Интернет челтәрендә Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башлыгы Ф. Р. Мәхмүтов